Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы салтык авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2019 елнын 11 феврале № 92

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге »
муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында » карар проекты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында " карар проектын кабул итәргә. (1 нче кушымта)

2. .“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты хакында «Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен” 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2019 елның 11 мартына Олы Салтык авылы мәдәният йорты бинасында «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча ачык тыңлаулар билгеләргә. Ачык тыңлауларны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 нче сентябрендәге 80 номерлы карары белән расланган ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе нигезендә үткәрергә.

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126;

-ТР,Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 нче йорт, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе Х.Х. Ибатов

Татарстан Республикасы  Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Салтык авыл
җирлеге Совет карарына1 нче кушымта
2019 елның  11 феврале   № 92

# Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты

1) 8 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

17) «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.»;

2) 32 маддәнең 6 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга ( Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың гомуми җыелышында, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларында, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; гамәлгә куючы (акционер) булган муниципаль берәмлек идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очраклар;».

3) 54 нче маддәгә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кулланучылар хокукларын яклау турында " 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра.»;

4) 90 нчы маддәнең 3 өлешендә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Җирлек халкы саны артуга яки кимүгә бәйле рәвештә, җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яки киметүче үзгәрешләр әлеге үзгәрешләр кертү

турында муниципаль норматив хокукый акт кабул иткән җирлек Советы вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.».

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве узу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән алынганнан соң түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61 нче йорт,

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы Рәисе Х.Х.Ибатов

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге
Совет карарына 2 нче кушымта
2019 елның 11 феврале №92

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр керту турында» Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы.

1. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында карар проектына тәкъдимнәр Кама Тамагы районының Олы Салтык авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Х.Такташ, 132нче йорт, яисә 8(84377) 35-8-19 факсы буенча, язма рәвештә, өстәмәләр таблицасы рәвешендә, түбәндәге үрнәк буенча:

| Пункт | Карар проекты тексты | Автор проекты тесты | төзәтмәләрне исәпкә алып | төзәтмә авторы (Ф. И.О, адресы, телефон, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 201 9 елнын 4 мартына кадәр 8дән 17 сәгатькә кадәр ,түбәндәге адреслар буенча билгеләнгән мәгълүмат стендларында карар игълан ителгән көннән башлап кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Х.Такташ урамы, 132нче йорт, шәхсән яисә почта аша («Устав турында фикер алышу» яисә «ачык тыңлаулар» тамгасы белән конвертта), шулай ук 8(84377)35-8-19 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә ачык тыңлауларны үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында теркәлә һәм карау өчен" Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Советына тапшырыла.